# КАРАР

2019 елның 28 ноябре, № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 26 ноябрендә үткән гражданнар җыены беркетмәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча:

Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылы территориясендә теркәлгән , балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны:

-Шепшенар авылына су башнясы сатып алу, китерү, урнаштыру һәм карап тоту эшләрен башкаруга юнәлтүгә ризамы ?:

« РИЗА» "КАРШЫ"

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 98 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 66 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча граңданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» дип гражданнар җыенында катнашучы 66 кеше тавыш бирде;
«юк» дип гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында узган гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – кабул ителгән дип танырга.

Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылы территориясендә теркәлгән , балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны:

-Шепшенар авылына су башнясы сатып алу, китерү, урнаштыру һәм карап тоту эшләрен башкаруга юнәлтүгә

« РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән.

3. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылып, гражданнар Җыенының нәтиҗәсен игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: www.pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ятмас Дусай Авылы Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Гарифуллина